ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.04.2021 № 316

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

– Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ (1 нче кушымта).

– Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 ел, 1 апрель, 316 нчы карарына 1 нче кушымта

**Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба - Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча даими эшләүче координация органы булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Нурлат муниципаль районының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең составы һәм тәртибе

2.1. Комиссия рәистән, комиссия әгъзаларыннан һәм җаваплы секретарьдан тора.

2.2. Комиссия рәисе булып Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тора. Комиссия рәисе булмаган чорда Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып тора.

## 3. Комиссиянең төп бурычлары, функцияләре, вәкаләтләре

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар ителгән затларны, шул исәптән җәмгыятькә интеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру:

- элеккеге тоткыннарны социаль яклау;
- һөнәри юнәлеш һәм хезмәт адаптациясе;
- торак һәм көнкүрешен төзү;
- медицина ярдәме:
- психологик ярдәм;

– югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләүнең башка формалары.

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген һәм хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итү.

3.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

3.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне булдырмауны профилактикалау.

3.5. Район территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү һәм хезмәт белән интеграцияләү буенча алып барыла торган эш турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

## 4. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә. Ведомствоара комиссия рәисе:

– ведомствоара комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;
– хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия, ведомствоара комиссия утырышын алып бара;
– ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен раслый; үз вәкаләтләре кысаларында ведомствоара комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
– ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;
– ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен ул шәхси җавап тота.

Ведомствоара комиссия секретаре:

– ул ведомствоара комиссия рәисе йөкләмәләрен үти:
– ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;
– ул ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;
– Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы учреждениеләре администрацияләреннән җәзаны үтәү системасы учреждениеләреннән алынучы мәгълүматны җыя һәм гомумиләштерә, әлеге

затны азат итү вакыты, аның торагы барлыгы яки юклыгы, хезмәткә сәләте һәм булган белгечлекләре булу турында мәгълүмат җыя;

– иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан, ресоциализациягә ярдәм итү турында гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыра;

– ул ресоциализация программасының һәр катнашучысына шәхси ярдәм күрсәтү картасын һәм шәхси ресоциализация чаралары үтәлеше буенча документлар һәм белешмәләр кертелүче шәхси эшнамәсен рәсмиләштерә;

– ирекләреннән мәхрүм ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

– ул муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып ала;

– ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи:

– министрлык ведомствоара комиссия рәисенең аның утырышлары нәтиҗәләре буенча бирелгән йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

– Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкына ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары вәкилләре керә ала (килешү буенча).

4.4. Ведомствоара комиссия составына моңа кадәр иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализациянең уңай тәҗрибәсе булган затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Нурлат районы прокуратурасы вәкиле катнаша ала (килешү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышына Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, ведомствоара комиссия составына кермәгән, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла ала.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## 5. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. 5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан, ресоциальләштерүдә ярдәм күрсәтү турындагы гаризалары килгән саен, әмма айга бер тапкырдан да ким булмаган

күләмдә уздырыла. Кирәк булган очракта, ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы инициативасы буенча (ведомствоара комиссия рәисе белән килештереп һәм сәркатиб тәкъдиме буенча) Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. 5.3. Ведомствоара комиссия утырышын ведомствоара комиссия рәисе алып бара, ә аның булмаганда яки аның кушуы буенча ведомствоара комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында хәбәр ителә, алардан ресоциальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашу максатчан дип танылачак башка затларга, утырыш көненә кадәр бер тәүлектән дә ким булмаган вакытта, максатчан хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында Нурлат районы прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы, анда аның составының яртысыннан күбрәге катнашу шарты үтәлгәндә, хокуклы булып тора**.**

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары рекомендация характерында була һәм утырышта катнашучыларга ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия булалар.

5.9. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча гына уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр турында белешмәләрне, әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка, игълан итәргә хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматлар тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары законнар нигезендә җаваплы.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында, ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.

## 6. Утырышларны әзерләү һәм уздыру

6.1 Комиссия утырышларын турыдан-туры әзерләү белән аның рәисе, рәис урынбасарлары һәм җаваплы сәркатип шөгыльләнә.

Комиссия эш планы нигезендә, мәсьәләләрне комиссия утырышларында карауга әзерләү өчен җаваплы комиссия әгъзалары барлык документларны һәм материалларны комиссия секретаре адресына мәсьәлә карала торган утырышка кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча тапшырырга тиешләр.

Каралучы мәсьәләләр буенча комиссия утырышына чакырылучылар Исемлеге, комиссия рәисенә җаваплы сәркатип әзерли һәм раслауга тәкъдим итә.

6.2. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән катнашырга бурычлы һәм үз вәкаләтләрен башка вазыйфаи затларга тапшырырга хокуклы түгел.

Комиссия әгъзасы утырышта була алмаса, ул бу хакта комиссия рәисенә алдан хәбәр итәргә тиеш.

Шул ук вакытта комиссия әгъзасы карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышында катнашучыларга җиткерелә һәм беркетмәдә чагылдырыла.

Комиссия утырышы барышында барлык әгъзалар да фикер алышына торган мәсьәлә буенча үз позициясен һәм тәкъдимнәрен белдерергә тиеш.

Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзалары санының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була.

## 7. Комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны рәсмиләштерү

7.1. Утырышларны үткәрү нәтиҗәләре буенча комиссия үз компетенциясенә кертелгән, тәкъдим итү характерындагы мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.

7.2. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

7.3. Комиссия карарлары, рәис һәм җаваплы сәркатип тарафыннан өч көн эчендә имзаланып, танышу өчен Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшырыла, шулай ук кабул ителгән карарлар нигезендә чаралар үтәргә тәкъдим ителгән органнар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерелә.

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 ел, 1 апрель, 316 нчы карарына 2 нче кушымта

**Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль адаптацияләү һәм ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хәмзин Р.Р. | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Нәфыйгина Л.М. | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Ганиева Г.В. | Нурлат муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркатибе, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гаврилов Л.В. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмидуллин Р.Ф. | РФ ҖҮФХИнең ТР буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалы начальнигы (килешү буенча) |
| Зыятдинов С.Р. | Нурлат шәһәре прокуроры, өлкән юстиция киңәшчесе (килешү буенча) |
| Сәгъдиев А.Р. | «Нурлат РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча) |
| Гайнетдинова Л.М. | «Нурлат районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Терентьева О.Г. | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Нурлат муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |